РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
Г.Тукая ул., д. 7, с. Шадки, 422096
тел.: (84360) 53-7-12,
E-mail: Sdk.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Г.Тукай ур., 7 нче йорт, Шәтке авылы, 422096
тел.: (84360) 53-7-12,
E-mail: Sdk.Tul@tatar.ru

ОКПО 94319624 ОГРН 1061675011914 ИНН/КПП 1619004482/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 15** **« 03 » ноября 2022 ел.**

**Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 22 июне 12 нче номерлы «Адресация объектына адрес бирү, андый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 июлендәге 1332 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Теләче муниципаль районы Шәтке авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 22 июне 12 нче номерлы «Адресация объектына адрес бирү, андый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Адресация объектына адрес бирү, андый адресны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына:

- 2.20 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрнең 2.15 пунктындагы"б", "д", "з" һәм "и" пунктчаларында күрсәтелгән документлар башкарма хакимиятнең Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында булган белешмәләрне бирүгә вәкаләтле федераль органы яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә "Роскадастр" гавами-хокукый компаниясе турында" Федераль закон нигезендә вәкаләтле орган соравы буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә төзелгән гавами-хокукый компания тарафыннан тәкъдим ителә.»;

- 3.3 пунктның 2  абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер электрон форма гарызнамәсен тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Бердәм портал тарафыннан гарызнамәнең электрон рәвештә тутырылган кырының корректлы булмавы ачыкланса, мөрәҗәгать итүчегә турыдан-туры гарызнамәнең электрон формасында  ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр ителә.»

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Ф.Г.Кадыйров

СОВЕТ ШАДКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1619000640